ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «30» декабреннән № 296

# Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының бәйрәм фейерверкларын кулланганда куркынычсызлыгы турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен бәйрәм итү чорында пиротехник эшләнмәләр файдалануга бәйле халыкның иминлеген тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 22 декабрендәге 1121 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Чишмә авылында бәйрәм фейерверклары үткәрү урынын Яңа Чишмә авылыннан Екатерина Бистәсе авылына торак пунктына таба 500 м ераклыкта билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен үтәп, бәйрәм фейерверкларын файдалану өчен мәйданчыкларны (стадионнарны, паркларны) беркетү үткәрергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Фасахов